Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының
Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы

# КАРАР

«25» сентябрь 2024 № 34

«Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 20 нояберенең 28 номерлы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2023 елның 20 нояберенең 28 номерлы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 4 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) 2025 елда – 1,2 процент; 2026 елда – 1,2 процент; 2027 елда – 1,2 процент гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларга) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган Исемлеккә кертелгән урыннарга карата.».

1.2. 2 пунктның 6 нчы пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Җирлек башлыгы /А.И. Шаймарданова/